**Татар әдәбияты тарихы һәм теориясе кафедрасы: үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге**

Татар әдәбияты тарихы һәм теориясе кафедрасы – татар факультетында олы тарихлы һәм фәнни егәрлекле гыйльми-педагогик берәмлекләрнең берсе. Үткәне юкның – киләчәге юк, ди халык. Халкыбызның акыл-тәҗрибәсе белән тудырылган бу гыйбарә үткәнгә сак караш, ихтирами-инсани мөнәсәбәт аша киләчәккә күз ташларга, үз урыныбызны билгеләргә ярдәм итә. Ә татар әдәбияты кафедрасының үткәне, алтарихы аеруча бай. Аның олы юл башы 1944 елда оешкан татар теле һәм әдәбияты кафедрасына барып тоташа. 1960 елда филологик юнәлеш тел гыйлеме һәм әдәбият белеме тармакларына аерылып, татар теле һәм татар әдәбияты кафедраларына нигез салына. Татар әдәбияты кафедрасы белән җитәкчелек итү 1951 елда ук уртак кафедраның мөдире вазифасын башкарган проф. Х.Госманга йөкләнә. 1975 елда аны доц. А.Яхин алмаштыра. Ә 1981 елдан 1999 елга кадәр проф. А.Әхмәдуллин татар әдәбияты кафедрасы мөдире булып эшли. 1999-2009 елларда бу вазифаны проф. Х.Миңнегулов башкара; аннан соң – доцент Т.Гыйлаҗев. Әгәр дә игътибарыбызны татар әдәбияты тарихы кафедрасы оешкан датага юнәлтсәк, димәк, аңа 2010 елда 50 ел булган, аның юбилей елы. Ә юбилей датасы, гадәттә, үткәннәрне күздән кичереп, барлап, узганнарга йомгак ясау һәм киләчәк хакында уйлану вакыты.

Барлыкка килгән һәрбер яңа күренешнең оешу, аякка басу вакыты булган кебек татар әдәбияты тарихы кафедрасына да беренче кыенлыкларны, авырлыкларны җиңәргә туры килә. Аның беренче чорларында нибары 2 фәннәр кандидаты (Х.Госман, Я.Агишев) эшли, уку-укыту процесының дәреслек-хрестоматияләр, уку-укыту әсбаплары белән тәэмин ителеше дә канәгатьләнерлек булмый. Аларга ярдәмгә өлкән буын әдәбиятчылардан М.Гайнуллин, Г.Кашшаф, Х.Ярми, Г.Халит кебек танылган галимнәр килә. Узган XX гасырның 1960-1980 еллары – гомумән татар әдәбияты белеменең гыйльми-тикшеренү юнәлешләре киңәеп, зур уңышларга ирешкән дәвер. Бу вакытта татар теле һәм әдәбияты бүлеге, шул исәптән татар әдәбияты кафедрасының да фәнни потенциалын ныгыту өчен шартлар, мөмкинлек тудырыла. Х. Госман, И. Нуруллин, алар артыннан М.Хәсәнов, Н. Юзиев фән докторы дәрәҗәсенә ирешәләр. Шуның нәтиҗәсендә талантлы яшьләрне фәнгә тарту юллары ачыла. Кафедра каршындагы аспирантурада әлеге докторлар кул астында фәнни эшләр язып, З.Мәҗитов, М.Мәһдиев, М.Бакиров, Ш.Садретдинов, Р.Мостафин, Х.Миңнегулов, Н.Лаисов, С.Хафизов һәм башкалар кандидатлык диссертациясе яклыйлар. Һәм аларның кайберләре кафедрага эшкә калдырыла, ә кафедра тарихында билгеле бер эз сызып калдырган бер өлеше, башка оешмага күчеп, яңа әдәби юнәлешләрнең фәнни концепциясен эшләп, әдәбият фәне үсешен тәэмин итәләр, мәсәлән, андыйлардан М.Хәсәнов, Н.Юзиев һ.б. Кафедра татар әдәбияты төрле чорларының үсеш закончалыклары белән бәйле булган мөһим фәнни мәсьәләләрне тикшерү белән шөгыльләнә.

Үзенең хезмәтләре, ирешкән казанышлары, фәнни ачышлары белән татар әдәбияты кафедрасының дәрәҗәсен билгеләгән абруйлы галимнәрнең берсе – **Хатип Госман** (1908-1992). Ул хәзерге татар әдәбият белемендә кафедрабыз галимнәре тарафыннан фәнни мәктәп кимәлендә яшәгән күп кенә тармакларда тәүге фәнни тикшеренүләр башлый. «Шагыйрь җанлы, фән өчен җанын фида кылган җитәкче үзе берничә юнәлештә эшләде. Иң беренче Һ.Такташ иҗатын, 1910-1920 еллар татар поэзиясен өйрәнде, берничә китап-монографияләр, дистәләгән башка хезмәтләр калдырды. Аннары Х.Госман урта гасырлар әдәби мирасыбызны өйрәнүгә күчте», – дип яза А.Әхмәдуллин [Әхмәдуллин, 2002; 142]. Шулай да әлеге галимнең иң мавыгып, нәтиҗәле эшләгән «яңа» сүз әйткән өлкәсе – татар шигыре төзелешедер, мөгаен. Бу юнәлештә ул үзенә бер юл ярып, меңьеллык шигъриятне өйрәнеп, гыйльми мәктәп тудыра. Аның «Шигырь төзелеше» (1973), «Төрки шигыренең борынгы тамырлары» (1984), «Урта гасырларда төрки шигырь» (1987) һ.б. хезмәтләре татар әдәбият белеменең җитди казанышлары булып тора. Мәгълүм идеологик һәм сәяси чикләүләргә карамастан, урта гасыр әдәби ядкярләрен, кульъязмаларны өйрәнүне көчәйтә барып, аларны текстологик яктан эшкәртеп, бастырып чыгару юнәлешендә эшне ул башлап җибәрә.

Бүгенге көндә урта гасыр татар әдәбияты буенча эшләгән Ә.Шәрипов, Х.Миңнегулов, Н.Хисамов, Р.Ганиева, М.Әхмәтҗанов, М.Гайнетдинов, З.Рәмиев, Җ.Зәйнуллин кебек фән докторлары барысы да диярлек Х.Госман мәктәбендә тәрбияләнгән күренекле галимнәр булып торалар.

Оста лектор, доцент, Г.Тукай иҗаты буенча белгеч Я.Агишев, Х.Госманнардан лекция тыңлаган язучы, тәнкыйтьче, әдәбият галиме **Ибраһим Нуруллин** (1923-1995) – XX йөз башы әдәби хәрәкәтен өйрәнүне яңа биеклекләргә күтәргән галим. Ул беренчеләрдән булып Яңарыш чоры милли сүз сәнгатен концептуаль планда тикшерә, әдәбиятның үз эчке закончалыкларына буйсынып, чорның әдәби аң үзенчәлекләренә дә таянып хәрәкәт итүен раслый. Татар әдәбиятында тәнкыйди реализмның барлыкка килүен һәм үсешен шушы юнәлештә өйрәнү нәтиҗәсендә туган «Реализм юлыннан» («Путь к реализму», 1971) монографик хезмәте татар-төрки дөньяда әдәбият белеменең җитди казанышы буларак кабул ителә.

Татар әдәбият белеменең мөстәкыйль фәнни юнәлеше булган Тукай гыйльмиятенең үсеше дә И.Нуруллинның фидакарьләрчә хезмәте белән тәэмин ителде: «Г.Тукай эстетикасы» (1956), «Г.Тукай иҗаты» (1964), «Габдулла Тукай» (1979, «Моңлы саз чыңнары», 2000).

И.Нуруллин «Образлар дөньясында» (1964), «Тормыш һәм сәнгать чынлыгы» (1983) дигән җыентыкларында әдәбият белемендә тәнкыйть һәм фән мөмкинлекләрен бергә тоташтырып, заман әдәби хәрәкәтенә, замандашлары иҗатына объектив бәя биргән, әдәби тәнкыйтькә җан өргән, аның йөзен билгеләгән шәхесләрнең берсе буларак таныла.

Кафедра тарихында тирән эз калдырган галимнәрнең берсе, һичшиксез, **Нил Юзиев** (1931-1996). Ул кафедрада эшләгән елларында кандидатлык һәм докторлык диссертацияләре язып яклый, поэтика турындагы хезмәтләре өчен

Г.Тукай бүләгенә лаек була. Г.Ибраһимов исемендәге институтка эшкә күчкәч, кафедра белән хезмәттәшлеген дәвам иттерә. Н.Юзиев күренекле текстолог, яхшы оештыручы, редактор буларак танылды.

Галим, язучы, тәнкыйтьче **Мөхәммәд Мәһдиевнең** дә (1930-1995) татар әдәбияты кафедрасы тарихында лаеклы үз урыны бар. Гаҗәеп дәрәҗәдә оста лектор, әдәби иҗатта үз сукмагын булдырган язучы М.Мәһдиев XX йөз башы татар әдәбияты, шушы чорда фән буларак формалашкан әдәби тәнкыйть тарихы буенча фәнни эзләнүләр алып бара. Татар публицистикасы һәм журналистикасының моңа кадәр архивларда күмелеп яткан битләрен актарып, җитди яңалыклар алып килә. Галимнең яңалык рухы белән сугарылып, архив материалларына, аерым эстетик күзәтүләргә бай булган «Әдәбият һәм чынбарлык: XX йөз башы татар әдәбияты тарихына яңа материаллар» (1987), «Релизмга таба: XX йөз башы татар әдәбияты чынбарлыкның чагылышы мәсьәләләре» (1989), «Социальные корни таланта: из истории татарской литературы в годы нового революционного подъема и первой империалистической войны» (1990) хезмәтләрендә фәнни ачышлары чагыла. Кафедра доценты, соңгы елларда татар әдәбиятыннан альтернатив дәреслекләр авторы, күренекле методист буларак танылган «РСФСРның атказанган мәдәният хезмәткәре» **Альберт Яхин** (1931-1910) белән берлектә «Халык иҗаты әсәрләрен система итеп тикшерү тәҗрибәсе: мәкаль, табышмак, җырлар» (1982) дигән монографик хезмәтен яза. Әдәби иҗаттагы уңышлары өчен М.Мәһдиевкә Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе (1990) һәм «Татарстан Республикасының халык язучысы» (1993) дигән мактаулы исем бирелә.

Шагыйрь җанлы **Зәет Мәҗитов** (1927-2000) – бөтен гомерен кафедрада эшләүгә багышлаган галимнәрнең берсе. Ул – күренекле шагыйрь Фатих Кәримнең тормыш юлын һәм иҗат эшчәнлеген яктырткан «Ф.Кәрим: тормыш юлы һәм иҗаты турында очерк» (1963), Бөек Ватан сугыш елларында татар поэзиясен тикшерүгә багышланган “Сугышчан поэзия” (1975), “Илең турында уйласаң” (2000) һ.б. китаплар авторы. Алардан тыш Х.Госман, И.Нуруллин, М.Мәһдиев, Ф.Ганиева, Н.Лаисов белән авторлыкта студентлар, мәктәп тел-әдәбият укытучылары һәм укучылары өчен әдәбият теориясеннән “Әдәбият белеменә кереш” (1980) методик әсбабын язуда катнаша.

Әдәбият галиме, доцент **Шәйхелислам Садретдинов** та (1936-1996) татар әдәбият белемен үстерүгә, әдәби мирасны барлауга үзеннән мәгълүм өлеш кертә. Галим, Х.Миңнегулов белән берлектә, остазлары Х.Госман эшен дәвам иттереп, «XIX йөз татар әдәбияты ядкярләре» (1982), «XIX йөз татар хрестоматияләре» (1982) китапларын нәшер итә. Аның XIX гасыр әдәбияты буенча күп ачышлары 9 нчы сыйныф әдәбият дәреслегендә дә чагылыш таба. Фәнни эшен XX гасыр башы әдәби хәрәкәтенең күренекле вәкилләреннән берсе С.Рәмиевнең иҗатын өйрәнү юнәлешендә дәвам итеп, шагыйрьнең тормыш юлына һәм рухи мирасына караган бай фактологик материалны фәнни әйләнешкә кертә. Ш.Садретдиновның «Сәгыйть Рәмиев иҗаты»

(1973), «Сәгыйть Рәмиев. Таң вакыты»(1980) дигән хезмәтләре шагыйрьне татар шигърияте күгендә үзенә лаеклы урынына куеп, киләчәк тикшеренүләр өчен юл сызып калдырды.

Бүгенге көндә кафедрада техник персоналлар һәм аспирантлардан тыш 9 кеше эшли: 4 филология фәннәре докторы, профессор (шулардан А.Г.Әхмәдуллин – Татарстан Фәннәр Академиясенең мөхбир-әгъзасы, Х.Й.Миңнегулов һәм М.Х.Бакировлар – Россия гуманитар фәннәр академиясенең хакыйкый әгъзасы), 5 филология фәннәре кандидаты – шуларның 3 се доцент, 1 се өлкән укытучы, 1 се ассистент.

Кафедра хәзерге вакытта татар филологиясе һәм тарихы факультеты, шулай ук рус филологиясе, журналистика һәм социология бүлекләре студентларына татар әдәбияты белеменең төп тармакларыннан, махсус, сайлау курсларыннан лекцияләр укый, гамәли дәресләр алып бара, факультетыбыз студентларының курс һәм диплом эшләренә җитәкчелек итә. Моннан тыш кафедра ихтыяри-зарури рәвештә Татарстан Республикасы һәм Россия югары уку йортларында татар әдәбиятын укытуны координацияләү вазифасын да үз өстенә ала. Галимнәр Чаллы, Алабуга, Әлмәт, Түбән Кама, Ижау, Батыр, Төмән һ.б. шәһәрләрдәге югары уку йортларындагы студентларга лекция укыйлар, дәүләт аттестация комиссиясенең рәисе сыйфатында, курс һәм диплом эшләре җитәкчеләре яки оппонент булып олы ярдәм итәләр. Моннан тыш кафедра галимнәре башка югары уку йортлары һәм оешмалар өчен яңа кадрлар, яңа фән кандидатлары, докторлары әзерләүдә зур хезмәт куя, диссертацион хезмәтләргә рәсми оппонентлар һәм рецензентлар буларак чыгыш ясый; төбәк, төбәкара, халыкара конференцияләрдә, конгрессларда, симпозиумнарда фәнни докладлар белән катнашалар.

Кафедра татар теле һәм әдәбияты укытучыларына даими рәвештә квалификацияле методик һәм ярдәм күрсәтеп, милли мәгарифне үстерүгә һәм яңартуга үзеннән зур өлеш кертә. Аерым алганда, бу өлкәдә хезмәте Татарстан Республикасы Мәгариф министрлыгының К.Насыйри исемендәге премиясе белән бәяләнгән А.Әхмәдуллин, А.Яхин, Х.Миңнегулов, Ш.Садретдинов, Ә.Закирҗановлар урта гомуми белем бирү мәктәпләре, гимназияләр, урта махсус уку йортлары өчен татар әдәбиятыннан дәреслекләр, уку-укыту әсбаплары, программаларның авторлары булып торалар. Аннан тыш кафедра галимнәре төрле оешмалар, фәнни-тикшеренү институтлары, Татарстан Язучылар берлеге, Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, Энциклопедия институты, Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты белән хезмәттәшлек итә. Татар энциклопедиясен, Г.Тукайның энциклопедик сүзлеген, Татар әдәбияты тарихының алты томлыгын, хәзерге яңа сигез томлыгын төзүдә үзләренең сизелерлек өлешен кертәләр.

Халыкара фәнни бәйләнешләр да кафедра гыйльми эшчәнлегенең мөһим аспекты булып тора. Кафедра укытучылары Төркиядәге Ататөрек Культура мәркәзе, Финляндиядәге «Ислам җәмгыяте», Ясәви исемендәге

Төркестан халыкара университеты, халыкара журналлар, нәшриятлар һ.б. оешмалар белән гыйльми бәйләнешләр урнаштырып, төрки әдәбиятлар тарихының 30 томлыгын, Төрки халыкларның әдәбиятлары энциклопедиясен һәм антологиясен төзү һәм башка халыкара программаларда актив катнаша.

Соңгы елларда татар әдәбияты кафедрасы төп фәнни юнәлеш буенча тикшеренү эшләрен дәвам итеп, татар сүз сәнгате үсешендәге милли үзенчәлекләр, әдәби багланышлар, типологик охшашлыклар проблемаларына да игътибарын арттырды.

Татар әдәбияты кафедрасының тарихында 1980 еллар яңа чорны, баскычны башлап җибәрә. Кафедрада әдәбият белеменең өлгергән проблемалары буенча фәнни-тикшеренү эшләре алып бару өчен мөмкинлекләр тудырыла. Монда әдәбият галиме, профессор **А.Әхмәдуллинның** оста оештыру сәләте, зур җитәкчелек тәҗрибәсе мөһим роль уйный. Галимнең фәнни эшчәнлегендә татар драматургиясенең барлыкка килүе һәм үсеше, хәзерге чор милли сәхнә әдәбиятында вәзгыять мәсьәләләре төп урынны алып тора, театр тәнкыйте белән драматургия тарихы синтезында күренекле драматургларның иҗат портретлары тудырыла. Милли сәхнә әдәбиятында мәгълүм роль уйнаган Фәтхи Бурнашның тормыш юлын һәм рухи мирасын өйрәнү юлында А.Әхмәдуллин зур көч куя. Галимнең зур фәнни эшчәнлеге унлап җитди хезмәтләрдә чагылыш таба: «Ничек сурәтләргә сине, замандаш?» (1976), «Татарская драматургия» (1983), «Горизонты татарской драматургии» (1983), «Фәтхи Бурнаш» (1988), «Дөреслеккә ирешү юлында» (1993), «Күңелләрне уятыр» (2007) һ.б. А.Әхмәдуллин кафедраның гыйльми юнәлеше буенча фәнни эшчәнлеген дәвам иттереп, «Татар драматургиясе тарихы»ның (2010) беренче кисәген язып тәмамлады. Аның шулай ук татар әдәбияты теориясе һәм методологиясе буенча публикацияләре бар. Хезмәтендә һәм әдәби гыйльми иҗатында ирешкән уңышлары өчен А.Әхмәдуллин «Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе» (1982), «Татарстанның атказанган фән эшлеклесе» (2002) дигән шәрәфле исемнәргә лаек булды.

Киң колачлы галимә, профессор, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе, Г.Тукай иҗаты буенча белгеч **Р.Ганиева** «Восточный Ренессанс и поэт Кул Гали» (1988) монографиясендә Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» дастанын Ренессанс (Яңарыш) ноктасыннан Шәрекъ һәм Гареб әдәби багланышлары яссылыгында шәрехли. Ул Урта гасыр һәм яңа чор татар һәм төрки әдәбиятлары традицияләренең һәм багланышларының фәлсәфи-эстетик һәм этик нигезләрен тикшерү юнәлешендә җитди эзләнүләр алып бара. XX гасыр башы татар әдәбиятының күренекле сүз художниклары Г.Тукай, Г.Исхакый, С.Рәмиев, Г.Ибраһимов һ.б.ларның иҗатлары да шушы ноктадан тикшерелә. Р.Ганиева – «Нәҗип Думави: Тормыш сәхифәләре» (1986, З.Рәмиев белән берлектә), «Шагыйрьнең рухи дөньясы» (2002), «Нәҗип Думавиның иҗат сәхифәләре» (2003), «Татар әдәбияты: традицияләр, багланышлар» (2002) һ.б. монографик хезмәтләр авторы.

Әдәбият фәнендә шигърият белеме тармагын иңләп өйрәнгән галим **М.Х.Бакировның** «Гомумтөркия поэзиясенең яралуы һәм иң борынгы формалары» (1999) дигән докторлык диссертациясе һәм тюркологлар тарафыннан танылып югары бәяләнгән «Шигърият бишеге» (2001) монографиясе борынгы сәнгатьнең генезисын-яралуын, синкретик табигатен, образ-сурәтләр даирәсен һәм сәнгати үзенчәлекләрен тарихи поэтика яссылыгында тикшерүгә багышланган. «Шигърият дөньясына сәяхәт» (1999) хезмәтендә фольклордан классик язма шигырьгә күчү тарихы гыйльми күзаллана. М.Бакиров фәнни эшчәнлегенең икенче зур тармагы – халык авыз иҗаты. Ул бу өлкәдә дә куәтле фәнни потенциалга ия галим булуын күрсәтте. Халык авыз иҗаты жанрлары, аларның үсеш эволюциясе, поэтикасы галимнең “Фольклор жанрларын система итеп тикшерү тәҗрибәсе” (1979, автордаш белән) монографиясендә һәм зур тәҗрибәгә таянып югары уку йортлары өчен язылган “Татар фольклоры” (2008) дәреслегендә яктыртыла. Аның татар әдәбият белемен, мәдәниятен үстерүгә керткән хезмәте «Татарстан Республикасының атказанган культура хезмәткәре» (1998), «Кол Гали исемендәге халыкара бүләге» (2002) дигән шәрәфле исемнәр белән бәяләнде.

Киңкырлы галим, Татарстанның һәм Россиянең атказанган фән эшлеклесе (1994, 2005) **Х.Миңнегуловның** «Шәрык һәм татар әдәбиятында кысалы кыйссалар» (1998) «Татарская литература и Восточная классика» (1993) монографияләре һәм докторлык диссертациясе урта гасыр татар әдәбиятын дәвамлы һәм максатчан өйрәнүе нәтиҗәсендә языла. Галим аларда төрки-татар сүз сәнгатенең гарәп-фарсы дөньясы белән күпгасырлык әдәби-мәдәни багланышларын киң тарихи-мәдәни һәм әдәби-эстетик планда тикшерә. Аның «Татарская литература и восточная классика» дигән монографиясе Татарстан Республикасының «Фән һәм техника өлкәсендәге Дәүләт премиясе»нә (1995) лаек була. Х.Миңнегулов – кафедраның иң актив һәм нәтиҗәле эшләгән галимнәреннән берсе. Аның соңгы унъеллыкта төрле чор татар әдәбиятының фәнни-гыйльми проблемаларын, халкыбыз рухи тормышының башка халыклар язма культурасы белән багланышларын, мөһаҗир язучыларның, аеруча Гаяз Исхакыйның мөһаҗирлектәге күптармаклы эшчәнлеген яктырткан дистәләгән китабы дөнья күрде: «Дөньяда сүземез бар» (1999), «Гасырлар өнен тыңлап» (2003), «Гаяз Исхакыйның мөһаҗирлектәге иҗаты» (2004), «Чит илләрдәге татар әдәбияты» (2007), «Записи разных лет» (2010), “Гасырлар арасында уйланулар” (2010 һ.б. Х.Миңнегулов Кол Гали һәм Гаяз Исхакый бүләкләре иясе.

Урта һәм яшь буын катламнарын тәшкил иткән галимнәрнең дә кафедраның гыйльми эшчәнлегендә һәм әдәби-мәдәни тормышында үз урыны бар. Хәзерге татар драматургиясенең үсеш тенденцияләре, яңарыш сыйфатлары, татар сәхнәсендәге эзләнүләр, җанлы әдәби процесс, татар әдәби тәнкыйтенең торышы һәм киләчәк перспективасы проблемалары Язучылар берлеге әгъзасы, доц. **Ә. Закирҗановның** гыйльми-тикшеренү

объектлары булып тора. Аның фәнни ачышлары, күзәтү-гомумиләштерүләре, «Мәктәптә татар әдәбиятын укыту мәсьәләләре» (1997), «Заман белән бергә» (2004), «Хәзерге татар драматургиясенең актуаль мәсьәләләре» (2010) хезмәтләрендә һәм мәкаләләрендә чагыла. Ә. Закирҗановның «Яңарыш юлыннан» (2008) монографиясе һәм кафедрада тикшерелеп яклауга тәкъдим ителгән «Хәзерге татар әдәбият белеме үсешенең төп юнәлешләре (1980-2010 еллар)» докторлык диссертациясендә әдәбият белеменең иң катлаулы мәсьәләләре, бу өлкәдәге эзләнүләрнең фәнни-теоретик, методологик нигезләре ачыклана, әдәбият гыйлеме тармакларының торышы, киләчәктә үсеш-үзгәреш юллары билгеләнә.

Доцент **Т.Гыйлаҗев** гыйльми эшчәнлегендә татар әдәби тәнкыйтенең барлыкка килүе һәм үсеше, XX гасыр башы милли әдәбиятының Яңарыш закончалыклары, андагы яңа әдәби күренешләрнең эстетик табигате һәм XX гасыр әдәбият белемендә мөстәкыйль фәнни тармак буларак формалашкан Тукай гыйльмиятенең үткән юлы тикшерелә. Галимнең «Татар әдәбияты тарихын укыту мәсьәләләре» (1999), «Әдәби мирас: тарих һәм заман» (2005), «Татар әдәбияты. XX гасыр башы» (2007), «Рецензияләрдән тәгъзияләргә. XX йөз башы татар әдәби тәнкыйте» (2008) һ.б. хезмәтләре аның фән дөньясында үз юлын табуы хакында сөйли.

Доц. **Р.Харрасова** Г.Исхакыйның башлангыч чор иҗатын рус-төрек әдәби бәйләнешләре контекстында «Әдәби бәйләнешләр яктылыгында» (2002) дигән монографиясендә тикшерә. Уку-укыту процессында күзәтелгән үзгәрешләр тәэсирендә галимә фәнни тикшеренү эшчәнлеген киңәйтеп, әдәби тәнкыйть һәм текст теориясе, әдәби редакцияләү, язучының иҗат лабораториясе кебек әдәбият фәненең яңа аспектларына үз игътибарын юнәлтте: «Иҗат лабораториясе» (2004), «Әдәби тәнкыйть теориясе» (2007), «Әдәби редакцияләү» (2007), «Татар матбугаты: бүген һәм иртәгә» (2010) һ.б. Р. Харрасова – Язучылар берлеге әгъзасы, талантлы каләм белән язылган дистәләгән шигырь, хикәя китаплары авторы.

Фил. фән. канд. **И.Гомәров** X1X гасыр мәгърифәтчелек әдәбиятының төп сыйфатлары, язучыларның чор сүз сәнгатенә алып килгән яңалыгы, татар әдәбиятында суфичылык күренешен фәлсәфи-эстетик табигате кебек фәнни проблемалар белән шөгыльләнә. «Мәгърифәт җырчысы» (2006) монографиясендә Гали Чокрыйның тормышы һәм иҗаты тикшерелә. Соңгы елларда әдәби чыганакчылык һәм текстология тармагы буенча уңышлы эшләп килә. Яшь галимнең, заман сулышын тоеп, фән дәрьясының моңа кадәр сукмак салынмаган катламнарында иҗади эзләнүләр алып барып, җитди нәтиҗәләргә ирешүе игътибарга лаек.

**Ч.Гыйлаҗева** татар әдәби-мәдәни дөньясында тирән эз калдырган галим Г. Сәгъдинең әдәби-тарихи мирасында әдәбият белеме мәсьәләләрен тикшерүгә багышланган кандидатлык диссертациясе яклады. Ул галимнең тормыш сукмакларын һәм күптармаклы эшчәнлеген «Габдрахман Сәгъди» (2006) хезмәтендә яктыртты, шулай ук авторлыкта «Габдрахман Сәгъди: фәнни-биографик җыентык» (2008) китабын әзерләп бастырып чыгарды.

Күренә ки, кафедраның илле еллык фәнни гыйльми-эшчәнлеге гаҗәеп дәрәҗәдә киңкырлы, ирешелгән казанышлар җитди һәм аны бер язма кысаларында гына тулаем иңләп алу да мөмкин түгел.

Әлбәттә, матур әдәбият, сәнгатьнең башка төрләренә караганда, иҗтимагый-сәяси үзгәрешләргә бик сизгер. 1980 елларның урталарында башланган Яңарыш хәрәкәте, хәбәрдарлык чоры әдәбиятчыларның, шул исәптән кафедраның гыйльми педагогик-методик эшчәнлеген тулаем яңача үзгәртеп коруны көн тәртибенә куйды. 1989 елда татар теле һәм әдәбияты бүлеге нигезендә факультет оешу кафедраның фәнни эшчәнлек кырларын тагын да киңәйтү, әдәби мирасны колачлап өйрәнү мөмкинлекләре бирде. Татар әдәбияты кафедрасы һәм Т. Галиуллин җитәкчелегендә оешкан татар теле һәм әдәбиятын укыту методикасы кафедрасы галимнәре-укытучылары тарафыннан әдәбият фәненең үсеше тәэмин ителде. Матур әдәбиятны тикшерү һәм бәяләүнең үзгәргән, яңартылган ориентирлары нигезендә кафедра әгъзасылары тарафыннан укытыла торган барлык фәннәрдән, махсус һәм сайлау курсларыннан программалар яңартылу җитди эш булды.

Уку-укыту процессына, классик университет диварларына да үтеп кергән кырыс базар шартлары әдәбият белемендә, гамәли файданы күз алдында тоткан тармаклар буенча эзләнүләрне көчәйтүне көн тәртибенә куйды. Бу өлкәләрдә дә җитди генә уңышларга ирешүне әйтергә кирәк.

Әдәбият фәненең тотрыклы эчке үсеш закончылыклары, таяну нокталары булса да, аңа заман рухы, аерым очракларда ахырына кадәр уйланып бетерелмәгән дәүләт карарлары, заман шаукымы сизелерлек тәэсир ясый. Россиянең Болон процессына, югары белем бирүнең Аурупа пространствосына кушылуы, шуның нәтиҗәсендә югары мәктәпләрдәге үзгәртеп кору хәрәкәте, күп баскычлы белем бирү системасына күчү, факультетның киләчәк перспективасы татар әдәбияты тарихы һәм теориясе кафедрасы алдына, аның гыйльми-фәнни педагогик-методик эшчәнлегенә яңадан-яңа бурычлар куя.

**Әдәбият**


1. *Азат Әхмәдуллин.* Офыклар киңәйгәндә. Әдәби-тәнкыйть мәкаләләре. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2002. – 239 б.
2. *Хатыйп Миңнегулов.* Гасырлар арасында уйланулар. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2010. – 222-241 б.